МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.10.2021 Казан шәһәре № 756

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 1 нояберендә 8053 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында 14 яшьтән 18 яшькәчә булган балигълык яшенә җитмәгән гражданнарны укудан буш вакытта, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзли торган 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 30 ноябрендәге 880 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында 14 яшьтән 18 яшькәчә булган балигълык яшенә җитмәгән гражданнарны укудан буш вакытта, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзли торган 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 30 ноябрендәге 880 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 10.06.2016 №337, 26.09.2018 №904, 05.03.2019 №158, 07.05.2019 №330, 14.11.2019 №1019, 29.06.2020 №468, 08.10.2020 №713 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның «13» октябрендәге 756 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында 14 яшьтән 18 яшькәчә булган балигълык яшенә җитмәгән гражданнарны укудан буш вакытта, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзли торган 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 30 ноябрендәге 880 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытында, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

1 һәм 2 пунктларда «урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзли торган 18 яшьтән 20 яшькәчә эшсез гражданнарны» сүзләрен «урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасында 14 яшьтән 18 яшькәчә булган балигълык яшенә җитмәгән гражданнарны укудан буш вакытта, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзли торган 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

исемендә «урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзли торган 18 яшьтән 20 яшькәчә эшсез гражданнарны» сүзләрен «урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны» сүзләренә алмаштырырга;

1 бүлектә:

1.1 пунктында «урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзли торган 18 яшьтән 20 яшькәчә эшсез гражданнарны» сүзләрен «урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында

документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктында «урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзли торган 18 яшьтән 20 яшькәчә эшсез гражданнарны» сүзләрен «урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнар (алга таба – белем алып, эше булмаган затлар)»;

1.4 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.7 пунктның ике пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән өстәргә:

«Татарстан Республикасы порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.»;

1.9 пунктның дүртенче абзацында «Федераль законның 2 ст. 1 п.« сүзләрен «Федераль законның 2 статьясының 3 пункты нигезендә тапшырылган» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Татарстан Республикасында 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытында, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру.

### 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждениесе) атамасы

Дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлекләре территориясендә халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте (алга таба – мәшгульлек үзәге) дәүләт учреждениеләре күрсәтә.

## 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып мөрәҗәгать итүчегә вакытлыча эшкә урнашу өчен 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык белән расланган формада юллама бирү (бирүдән баш тарту) тора.

## 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы

Мәшгульлек үзәгенә беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь рөхсәт ителгән вакыты 20 минуттан артмаска тиеш.

Мөрәҗәгать итүчеләр алга таба мөрәҗәгать иткән очракларда дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь рөхсәт ителгән вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Мөрәҗәгать итүчеләр белән килештерү телефон яки электрон элемтә чараларын, шул исәптән Интернет челтәрен, почта элемтәсен дә кертеп, гаризаны теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Мөрәҗәгать итү датасы һәм вакыты алдан килештерелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне көтү вакыты 5 минуттан артмаска тиеш.

Мөрәҗәгать итүчеләр күпфункцияле үзәккә, ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткән очракта, гаризаны мәшгульлек үзәгенә тапшыру күпфункцияле үзәк белән мәшгульлек үзәге арасындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә срокларда, ләкин гаризаны теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

## 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар булып түбәндәгеләр тора:

- 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкның 13 нче кушымтасындагы форма буенча халыкка эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза яки 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкның 14 нче кушымтасындагы форма буенча мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан бирелгән, халыкны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим) һәм мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимгә ризалыгы;

- Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алмаштыра торган документ (Россия Федерациясе гражданнары өчен);

- чит ил гражданиның шәхесен таныклаучы документ (чит ил гражданнары өчен);

- гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документ (гражданлыгы булмаган затлар өчен).

Документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан факсимиль элемтә чараларын кулланып яисә электрон формада гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән Интернет челтәре, Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы аша җибәрелә ала.

### 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуында торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә дә, аларны тапшыру тәртибе

Ведомстволар арасында электрон хезмәттәшлек итү тәртибендә алына торган документлар:

- индивидуаль тернәкләндерү программасыннан өземтә, инвалидлык билгеләнү фактын раслый торган белешмә, шулай ук организмындагы бозылган функцияләрне һәм яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, инвалид өчен медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлап алу өчен кирәкле белешмәләр (кешенең организмында авырулар, травма алу һәм дефектлар нәтиҗәсе белән аңлатыла торган бозылган функцияләрне исәпкә алып, күрсәтелгән һәм күрсәтелмәгән хезмәт эшчәнлеге төрләре турында; инвалидны эшкә урнаштыру өчен махсус эше урыны җиһазлау (тәэмин итү) буенча; эшкә яраклаштыру буенча; эш шартлары турындагы киңәшләр белән);

- инвалидның организмындагы бозылган функцияләрен һәм яшәешендәге чикләүләрен исәпкә алып, киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлау өчен белешмәләр (индивидуаль тернәкләндерү программасыннан өземтә);

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документ-ларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүмат-ларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;

документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булуы.

### 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләрнең булмавы тора:

- Россия Федерациясе гражданины паспортының яки аны алмаштыра торган документның (Россия Федерациясе гражданнары өчен);
- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын раслаучы документларның (чит ил гражданнары өчен);
- гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документларның (гражданлыгы булмаган затлар өчен).

### 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

### 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

Мөрәҗәгать итүче мәшгульлек үзәгенә беренче тапкыр шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте чират тәртибендә күрсәтелә. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән очракта чират көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Вакыты һәм датасы алдан килештерелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне көтү вакыты 5 минуттан артмаска тиеш.

### 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза гариза һәм документлар алынган көнне теркәлә.

Гариза һәм кирәкле барлык документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – мәшгульлек үзәгенең ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.

Гаризаны теркәү мәшгульлек үзәге тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар – физик затлар регистрына мөрәҗәгать итүче тапшырган документларда булган белешмәләрне исәпкә алу язуының теркәү номерын беркетеп кертү дигән сүз. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча гаризаны кабул итү датасы һәм исәпкә алу язуының теркәү номеры турында белешмәләрне үз эченә алган гариза күчермәсе бирелә ала.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.7 пунктының 1 пунктчасында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган

инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктalы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-ноктalы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль

хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) яки күрсәтеп булмау мөмкинлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:

Үзәк бүлекчәсе бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;

мөрәҗәгать итүче өчен индивидуаль яки гавами (телдән яки язмача) мәгълүмат бирү рәвешендә (шәхси кабул иткәндә, телефон элемтәсе, электрон почта чараларын кулланып, массакүләм мәгълүмат чараларында мәкаләләр, мәгълүмати материаллары (брошюралар, белешмәлекләр, буклетлар һ.б.) нәшер итү юлы белән) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү үрнәкләре турында Татарстан Республикасы порталында мәгълүмат урнаштыру мөмкинлеге;

мөрәҗәгать итүче өчен дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаларның һәм башка документларның формаларын алуны, шул исәптән аларны күчереп алу һәм электрон рәвештә тутыру мөмкинлеге белән дә, тәэмин итү;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтү вакытының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, шул исәптән телефон элемтәсе, электрон почта аша, Татарстан Республикасы порталы, күпфункцияле үзәк аша, ерактагы эш урыны, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында мәгълүмат алу мөмкинлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

мәшгульлек үзәге тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү турында Россия Федерациясе законнарындагы мәҗбүри таләпләрнең, дәүләт хезмәте күрсәткәндә әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлеше;

дәүләт хезмәте күрсәтү срокларының үтәлүе;

әлеге Регламентта билгеләнгән административ процедураларның эзлеклелеге саклану;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезлелеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләсе буенча нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы.

Мөрәҗәгать итүченең мәшгульлек үзәге белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

документларны почта аша җибәргәндә, шул исәптән электрон документ формасында – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең мәшгульлек үзәге белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

Күпфункцияле үзәктә, ерактагы эш урынында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гариза теркәлгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча мәшгульлек үзәгенә тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр

Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүдән тыш, электрон формада күрсәтелми.

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар – физик затлар регистрында үзләре турында белешмәләр булган гражданнар өчен, өч көн эчендә мәшгульлек үзәгенә килү тәкъдиме белән, телефон яки электрон элемтә чараларын кулланып, җәмәгать эшләрендә катнашу өчен буш эш урыны (вакантлы вазыйфа) булуы турында эш бирүчедән белешмәләр алынуы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге тудырыла.

Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар мәшгульлек үзәге бүлекчәсенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан мәшгульлек үзәгенә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закондагы (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.»;

3 нче бүлектә:

Аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм

вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны (гамәлләрне) дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре.

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Гражданинның дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза белән мөрәҗәгать итүче яки мәшгульлек үзәге тарафыннан бирелгән дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдим белән ризалашуы административ процедураны башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итүче (шәхсән яки телефон аша) яисә язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итә.

Телдән мөрәҗәгать иткән очракта, мәшгульлек үзәге белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча да, һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әгәр гражданин мөрәҗәгатькә язмача җавап алырга тели икән, мәшгульлек үзәге белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча да, язмача консультация бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.»;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә документларны кабул итүдән баш тарту

Административ процедураны башкару өчен гражданинның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгате нигез булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза мәшгульлек үзәгенә күпфункцияле үзәк, ерактагы эш урыны, почта элемтәсе, факсимиль элемтә чараларын кулланып яисә электрон формада, шул исәптән Бердәм портал яки Татарстан Республикасы порталын кулланып җибәрелгән очракта, гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булган очракта, гаризаны кабул итүдән баш тарту сәбәбен күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә хәбәр җибәрә.

Үтәү вакыты: процедуралар гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла. Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә гаризаны кабул итүдән баш тарту турында язмача хәбәр итү.»;

3.5.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.2. Гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру мөмкинлеге турында мәгълүмат җыю һәм анализлау

Эш бирүченең гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында язмача тәкъдим (гариза) белән мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итүче административ процедураны үти башлау нигезе булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече мәгълүматны җыя һәм анализлый, түбәндәгеләрне исәпкә алып:

икътисад эшчәнлеге, оешмаларның финанс-икътисад торышы төрләре буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге (алга таба – муниципаль берәмлек) территориясендә урнашкан оешмалар һәм хезмәткәрләр санының бүленешен;

кадрларның һөнәри үсеш программаларын анализлау, хезмәт ресурсларына ихтыяҗның һөнәри-квалификация структурасын фаразлау нәтиҗәләрен;

муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш перспективаларыннан чыгып, эш бирүчеләрнең хезмәт ресурсларына булган ихтыяҗын бәяләүне;

алган белем, һөнәри-квалификация структурасы, туры килә торган эш эзләүнең дәвамлылыгы, билгеле бер категория гражданнарына бәйле рәвештә эшкә урнашуга комачаулый торган сәбәпләр, туры килә торган эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган гражданнарның составын;

тормыш эшчәнлеге чикләнгән гражданнар өчен инфраструктураның үтемлелеген;

вакытлыча эшкә урнашуда катнашу буенча гражданнар арасындагы ихтыяҗны;

гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру буенча эш бирүчеләр һәм җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен;

гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру срокларын һәм дәвамлылыгын;

гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру шартларын;

гражданинның яшәү урыныннан вакытлыча эшкә урнашу урыныннан булган ераклыкны.»;

3.6.2 һәм 3.6.3 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2. Балигъ булмаганнарны вакытлыча эшкә урнаштыру мөмкинлеге турында мәгълүмат җыю һәм анализлау

Эш бирүченең балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында язмача тәкъдим (гариза) белән мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итүче административ процедураны үти башлау нигезе булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече мәгълүматны җыя һәм анализлый, түбәндәгеләрне исәпкә алып:

икътисад эшчәнлеге, оешмаларның финанс-икътисад торышы төрләре буенча муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан оешмалар һәм хезмәткәрләр санының бүленешен;

муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш перспективаларыннан чыгып, эш бирүчеләрнең хезмәт ресурсларына, вакытлыча характерга ия эшләрне башкаруга булган ихтыяҗын бәяләүне;

социаль яклауга аеруча мохтаҗларның билгеле бер категориясенә карап,

балигъ булмаган гражданнарның составын;

тормыш эшчәнлеге чикләнгән балигъ булмаган гражданнар өчен инфраструктураның үтемлелеген;

вакытлыча эшкә урнашуда катнашу буенча балигъ булмаган гражданнар арасындагы ихтыяҗны;

балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру буенча эш бирүчеләр һәм җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен;

балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру срокларын һәм дәвамлылыгын;

балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру шартларын;

балигъ булмаган гражданинның яшәү урыныннан вакытлыча эшкә урнашу урынына кадәрге араның ераклыгын.

3.6.3. Балигъ булмаганнарны вакытлыча эшкә урнаштыру өчен эш бирүчеләрне сайлап алу

Эш бирүченең балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында язмача тәкъдим (гариза) белән мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итүче административ процедураны үти башлау нигезе булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече эш бирүчеләрне аларның балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә алуны оештыру турындагы язма тәкъдимнәре (гаризалары) нигезендә сайлап ала, түбәндәгеләрне исәпкә алып:

булдырыла торган эш урыннары санын һәм үзләре өчен вакытлыча эшкә урнаштыру оештырыла торган балигъ булмаган гражданнар санын;

эш бирүченең индивидуаль тернәкләндерү программасын исәпкә алып, инвалид бала өчен эш урыны һәм хезмәт шартлары булуын яки булдыру мөмкинлеген;

балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру өчен транспорт белән тәэмин итү мөмкинлеген;

балигъ булмаганнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру шартларын;

гражданинның категориясенә һәм яшенә карап, балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру срокларын һәм дәвамлылыгын;

эш бирүче тарафыннан хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлүен;

эшчәнлек (һөнәр), эшкә урнашу, һөнәри белем бирү өлкәсен сайлау максатларында эш бирүченең балигъ булмаган гражданнарның һөнәри ориентациясендә катнашу мөмкинлекләрен бәяләүне;

эш бирүченең балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны финанслау өчен акчалары булуын.

Үзенә карата килешү төзү турында карар кабул ителә торган эш бирүчене билгеләү критерийлары:

аның тарафыннан шундый ук эшне башкарганда башка эш бирүчеләр белән чагыштырмача хезмәткә аеруча югары түләү тәкъдим ителүе;

шундый ук эшне башкарганда тәкъдим ителә торган эш хакының күләме бер үк суммада булган очракта, гаризаның мәшгульлек үзәгенә башка эш бирүчеләргә караганда алданрак тапшырылган булуы (гаризаны мәшгульлек үзәгендә теркәү

датасы буенча).

Үтәү вакыты: гариза мәшгульлек үзәгендә теркәлгәннән соң җиде эш көне эчендә карала. Кабул ителгән карар турында эш бирүчегә белдерү гаризаны теркәгәннән слң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек срокта җиткерелә.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза карау нәтиҗәләре буенча эш бирүче белән килешү төзү яки төзүдән баш тарту турында карар кабул итү һәм эш бирүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр җибәрү.»;

3.7.2 һәм 3.7.3 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7.2. Эшсез гражданнарны һәм белем алган эшсез затларны вакытлыча эшкә урнаштыру мөмкинлеге турында мәгълүмат җыю һәм анализлау

Эш бирүченең гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында язмача тәкъдим (гариза) белән мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итүче административ процедураны үти башлау нигезе булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече мәгълүматны җыя һәм анализлый, түбәндәгеләрне исәпкә алып:

икътисад эшчәнлеге, оешмаларның финанс-икътисад торышы төрләре буенча муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан оешмалар һәм хезмәткәрләр санының бүленешен;

кадрларның һөнәри үсеш программаларын анализлау, хезмәт ресурсларына ихтыяҗның һөнәри-квалификация структурасын фаразлау нәтиҗәләрен;

муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш перспективаларыннан чыгып, эш бирүчеләрнең хезмәт ресурсларына булган ихтыяҗын бәяләүне;

алган белем, һөнәри-квалификация структурасы, туры килә торган эш эзләүнең дәвамлылыгы, билгеле бер категория гражданнарына бәйле рәвештә эшкә урнашуга комачаулый торган сәбәпләр, туры килә торган эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган гражданнарның составын;

тормыш эшчәнлеге чикләнгән гражданнар өчен инфраструктураның үтемлелеген;

вакытлыча эшкә урнашуда катнашу буенча гражданнар арасындагы ихтыяҗны;

эшсез гражданнарны һәм белем алган эшсез затларны вакытлыча эшкә урнаштыру буенча эш бирүчеләр һәм җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен;

эшсез гражданнарны һәм белем алган эшсез затларны вакытлыча эшкә урнаштыру срокларын һәм дәвамлылыгын;

эшсез гражданнарны һәм белем алган эшсез затларны вакытлыча эшкә урнаштыру шартларын;

эшсез гражданинның һәм белем алган эшсез затның яшәү урыныннан вакытлыча эшкә урнашу урынына кадәрге аралыкның ераклыгын.

3.7.3. Эшсез гражданнарны һәм белем алган эшсез затларны вакытлыча эшкә урнаштыру өчен эш бирүчеләрне сайлап алу

Эш бирүченең гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында язмача тәкъдим (гариза) белән мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итүче административ процедураны үти башлау нигезе булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече эш бирүчеләрне аларның эшсез гражданнарны һәм

белем алган эшсез затларны вакытлыча эшкә алуны оештыру турындагы язма тәкъдимнәре (гаризалары) нигезендә сайлап ала, түбәндәгеләрне исәпкә алып:

булдырыла торган эш урыннары санын һәм үзләре өчен вакытлыча эшкә урнаштыру оештырыла торган гражданнар санын;

эш бирүченең индивидуаль тернәкләндерү программасын исәпкә алып, инвалид өчен эш урыны һәм хезмәт шартлары булуын яки булдыру мөмкинлеген;

гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру урынына транспорт үтемлелеген;

эшсез гражданнарны һәм белем алган эшсез затларны вакытлыча эшкә урнаштыру шартларын;

гражданинның категориясенә карап, вакытлыча эшкә урнаштыру срокларын һәм дәвамлылыгын;

эш бирүче тарафыннан хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлүен;

вакытлыча эшкә урнашу чоры тәмамланганнан соң гражданинны даими эш урынына урнаштыру мөмкинлеген бәяләүне;

эш бирүчедә эшсез гражданнарны һәм белем алган эшсез затларны вакытлыча эшкә урнаштыруны финанслау өчен акча булуын.

Үзенә карата килешү төзү турында карар кабул ителә торган эш бирүчене билгеләү критерийлары:

шундый ук һөнәрләр (белгечлекләр) буенча яисә шундый ук эшне башкарганда башка эш бирүчеләр белән чагыштырганда хезмәт өчен югарырак түләү дәрәҗәсен тәкъдим итүе;

шундый ук һөнәрләр (белгечлекләр) буенча яисә шундый ук эшне башкарганда тәкъдим ителә торган эш хакының күләме бер үк суммада булган очракта, гаризаның мәшгульлек үзәгенә башка эш бирүчеләргә караганда алданрак тапшырылган булуы (гаризаны мәшгульлек үзәгендә теркәү датасы буенча).

Үтәү вакыты: гариза мәшгульлек үзәгендә теркәлгәннән соң җиде эш көне эчендә карала. Кабул ителгән карар турында эш бирүчегә белдерү гаризаны теркәгәннән слң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек срокта җиткерелә.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза карау нәтиҗәләре буенча эш бирүче белән килешү төзү яки төзүдән баш тарту турында карар кабул итү һәм эш бирүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр җибәрү.»;

3.8.3-3.8.10 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.3. Мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләр турында мәгълүмат бирү:

гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру тәртибе, шартлары һәм сроклары;

вакытлыча эшкә урнашу вариантларыннан баш тарткан очракта, хокукый нәтиҗәләр;

гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорында матди ярдәм күрсәтү тәртибе һәм шартлары.

Мәшгульлек үзәге тарафыннан гражданинга туры килә торган вакытлыча эшкә урнашу вариантларын билгеләү административ гамәлләрне үти башлау өчен нигез булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече гражданинга түбәндәгеләр турында телдән мәгълүмат җиткерә:

гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру тәртибе, шартлары һәм сроклары турында;

вакытлыча эшкә урнашу вариантларыннан баш тарткан очракта, хокукый нәтиҗәләр турында;

гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорында матди ярдәм күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында;

вакытлыча эшкә урнашу вариантын сайлаган вакытта, аларны документаль раслаган очракта, гаризадагы мәгълүматларның исәпкә алынуы турында.

Үтәү вакыты: процедура процедура башлангач ике минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданнарга дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат бирү.

3.8.4. Мөрәҗәгать итүчегә Эш бирүчеләр регистрындагы мәгълүматларга карап, төзелгән килешүләр нигезендә гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру өчен буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында вакытлыча эшкә урнашу вариантларын сайлау

Гражданинның вакытлыча эшкә урнашу тәртибе һәм шартлары белән ризалашуы административ гамәлне үти башлау нигезе булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече гражданинга, Эш бирүчеләр регистрындагы гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру өчен буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турындагы белешмәләргә карап, мәшгульлек үзәге белән эш бирүчеләр арасында төзелгән килешүләр нигезендә вакытлыча эшкә урнаштыру вариантларын сайлый.

Мәшгульлек үзәге белгече гражданинга, һөнәрен (белгечлеген), вазыйфасын, эшчәнлек төрен, һөнәри әзерлеген һәм квалификация дәрәҗәсен, эш тәҗрибәсен һәм күнекмәләрен, индивидуаль тернәкләндерү программасында булган хезмәт характеры һәм шартлары турында киңәшләрне исәпкә алып, вакытлыча эшкә урнаштыру вариантларын сайлый.

Вакытлыча эшкә урнаштыру вариантларын сайлаганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

- эш урынына транспорт белән бару мөмкинлеген тәэмин итә торган җәмәгать транспорты челтәре үсешен исәпкә алмыйча, эш урыннарына юллау;

- хезмәт шартлары хезмәт сагы кагыйдәләре һәм нормаларына туры килми торган эш тәкъдим итү.

Эш бирүчеләр регистрында вакытлыча эшкә урнашу вариантлары булган очракта, мәшгульлек үзәге белгече вакытлыча эшкә урнаштыру өчен буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында мәгълүматны үз эченә алган исемлекне бастырып чыгара һәм гражданинга тәкъдим итә.

Вакытлыча эшкә урнаштыру вариантлары булмаган очракта, мәшгульлек үзәге белгече гражданинга туры килә торган эшне Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга – туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 419 номерлы боерыгы

белән расланган Гражданнарга – туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты нигезендә сайларга тәкъдим итә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң ике минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданин тарафыннан вакытлыча эшкә урнашу өчен буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында мәгълүматлар тупланган исемлекне алу.

3.8.5. Вакытлыча эшкә урнашу вариантларын мөрәҗәгать итүче белән килештерү

Мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан гражданинга туры килә торган вакытлыча эшкә урнашу вариантларын формалаштыру административ гамәлләрне үти башлау өчен нигез булып тора.

Гражданин мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим иткән исемлектән вакытлыча эшкә урнашу вариантларын сайлый һәм эш бирүчегә әңгәмәгә юллану өчен риза булуы (булмавы) турында белдерә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданин тарафыннан мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим иткән исемлектән вакытлыча эшкә урнашу вариантын сайлау.

3.8.6. Эш бирүче белән мөрәҗәгать итүче кандидатурасын килештерү

Гражданин тарафыннан тәкъдим ителгән исемлектән вакытлыча эшкә урнашу вариантын сайлау һәм эш бирүчегә әңгәмә үтү өчен юллануга ризалык белдерү административ гамәлне үти башлау өчен нигез булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече гражданин сайлап алган вакытлы эшкә урнашу вариантлары нигезендә телефон аша гражданинны әңгәмә үтү өчен юллауны эш бирүче белән килештерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында гражданинга телефон яки видеоэлемтә аша, Интернет челтәрен кулланып әңгәмә үткәрү мөмкинлеге тәэмин ителә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң ике минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүче белән гражданинны әңгәмәгә җибәрүне килештерү яки Интернет челтәреннән файдаланып, телефон яки видеоэлемтә аша әңгәмә үткәрү.

3.8.7. Мөрәҗәгать итүчегә вакытлыча эшкә урнашуга икедән артмаган юллама рәсмиләштерү һәм бирү

Административ гамәлне үти башлау өчен гражданинның үз кандидатурасын килештергән эш бирүче янына вакытлыча эшкә урнашу максатларында әңгәмә үтү өчен баруга ризалык белдерүе нигез булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече гражданинга 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлык боерык белән расланган форма буенча вакытлыча эшкә урнашуда катнашу өчен бер үк вакытта икедән артмаган юллама рәсмиләштереп бирә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданинга вакытлыча эшкә урнашуга юллама рәсмиләштерү һәм бирү.

3.8.8. Мөрәҗәгать итүчегә эш бирүченең тамгасы белән эшкә бирелгән юлламаны һәм, төзелгән очракта, билгеле бер вакытка төзелгән хезмәт килешүен мәшгульлек үзәгенә тапшыру кирәклеге турында мәгълүмат җиткерү

Гражданинга вакытлыча эшкә урнашуга юллама бирү административ гамәлне үти башлау өчен нигез булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече гражданинга юллама бирелгән көннән башлап өч көн эчендә вакытлыча эшкә урнашу мәсьәләсе буенча эш бирүче белән әңгәмә узарга кирәклеге һәм эш бирүченең әңгәмә нәтиҗәләре турындагы тамгасы белән вакытлыча эшкә урнашуда катнашу өчен бирелгән юлламаны мәшгульлек үзәгенә тапшырырга кирәк булуы турында хәбәр итә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданинга әңгәмә узу вакытлары һәм эш бирүче тамгасы белән вакытлыча эшкә урнашуда катнашу өчен бирелгән юлламаны тапшыру кирәклеге турында хәбәр итү.

3.8.9. Мөрәҗәгать итүче вакытлыча эшкә урнашу вариантыннан баш тарткан очракта рәсмиләштерү

Административ гамәлне үти башлау өчен гражданинның мәшгульлек үзәге тәкъдим иткән вакытлыча эшкә урнашу варианты белән килешмәве тора.

Гражданин вакытлыча эшкә урнашу варианты белән килешмәвен язмача белдерә һәм шәхси имзасы белән баш тарту фактын раслый.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гражданинның тәкъдим ителгән эш вариантларыннан язмача баш тартуы.

3.8.10. Әлеге пунктның 3-8 пунктчаларында каралган административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү нәтиҗәләрен Физик затлар регистрына кертү

Административ гамәлне үти башлау өчен мәшгульлек үзәге белгеченең әлеге пунктның 3-8 пунктчаларында күрсәтелгән карарларны кабул итүе нигез булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече Физик затлар регистрында түбәндәгеләрне терки:

- дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен (гражданинга вакытлыча эшкә урнашуда катнашу өчен юллама бирүне, вакытлыча эшкә урнашу вариантыннан баш тартуын).

Үтәү вакыты: процедура әлеге Регламентның 3.8.7, 3.8.9 пунктларында каралган процедураларның берсе тәмамланганнан соң бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Физик затлар регистрында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен теркәү»;

3.9.2-3.9.9 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.2. Әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның булуын тикшерү

Алга таба тагын мөрәҗәгать иткәндә, гражданинның мәшгульлек үзәгенә

шәхсән баруы административ гамәлне үти башлау нигезе булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече:

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның булуын тикшерә;

тапшырылган документлар нигезендә әлеге Регламентның 2.8 пункты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү яисә күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә;

мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, мәшгульлек үзәге белгече баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен аңлата, әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасындагы форма буенча 2 нөсхәдә язмача формада баш тарту турында карар рәсмиләштерә, аларның берсе мәшгульлек үзәгендә кала, икенчесе гражданинга бирелә.

Баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта, мәшгульлек үзәге белгече агымдагы архивтан гражданинның шәхси мәгълүматлары буенча элек тутырылган хисап документлары бланкларын ала.

Үтәү вакыты: процедура бер минут эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар яисә мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтүдән язмача баш тартуы.

3.9.3. Алга таба мәшгульлек үзәгендә барганда бирелгән вакытлыча эшкә урнашу юлламалары буенча эшкә алучы янына бару нәтиҗәләре турындагы белешмәләрне Физик затлар регистрына кертү

Административ гамәлне үти башлау өчен гражданин тарафыннан мәшгульлек үзәгенә алданрак барганда бирелгән, вакытлыча эшкә урнашуда катнашу өчен эш бирүче тамгасы куелган юлламаны мәшгульлек үзәге хезмәткәренә тапшыруы нигез булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече:

вакытлыча эшкә урнашуда катнашу өчен эш бирүчеләр тарафыннан тамгаланган юнәлешләрне кабул итә яисә алдагы килүдә бирелгән исемлек буенча мөрәҗәгать итүченең эшкә алучы янына бару нәтиҗәләрен ачыклый һәм эшкә алучы янына бару нәтиҗәләрен Физик затлар реестрында терки.

Үтәү вакыты: процедура процедура башланганнан бирле бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүче янына бару нәтиҗәсен Физик затлар регистрында теркәү.

3.9.4. Эшкә алучы вакытлыча эшкә урнаштырудан баш тарткан очракта, әлеге Регламентның 3.8.1 пунктының 3-9 пунктчаларында каралган административ процедураларны гамәлгә ашыру

Мәшгульлек үзәге белгече әлеге Регламентның 3.8.4-3.8.10 пунктларында билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге нигезендә:

Эш бирүчеләр регистрында булган, төзелгән килешүләр нигезендә вакытлыча эшкә урнашуда катнашу өчен буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турындагы белешмәләргә карап, мөрәҗәгать итүчегә вакытлыча эшкә урнашу вариантларын

сайлый;

вакытлыча эшкә урнашу вариантларын мөрәҗәгать итүче белән килештерә;

эш бирүче белән мөрәҗәгать итүченең кандидатурасын килештерә;

мөрәҗәгать итүчегә вакытлыча эшкә урнашуга икедән ким булмаган юллама рәсмиләштерә һәм бирә;

мөрәҗәгать итүчегә эш бирүченең тамгасы белән эшкә бирелгән юлламаны һәм, төзелгән очракта, билгеле бер вакытка төзелгән хезмәт килешүен мәшгульлек үзәгенә тапшыру кирәклеге турында мәгълүмат җиткерә;

мөрәҗәгать итүче эшкә урнаштыру вариантлары белән риза булмаган очракта, вакытлыча эшкә урнаштыру вариантыннан баш тарту рәсмиләштерә;

Физик затлар регистрында административ процедураларны үтәү нәтиҗәләрен терки.

Үтәү вакыты: процедуралар мөрәҗәгать итүче кабат мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәләре:

гражданин тарафыннан вакытлыча эшкә урнашу өчен буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында мәгълүматлар тупланган исемлекне алу;

гражданин тарафыннан мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим иткән исемлектән вакытлыча эшкә урнашу вариантын сайлау;

эш бирүче белән гражданинны әңгәмәгә җибәрүне килештерү яки Интернет челтәреннән файдаланып, телефон яки видеоэлемтә аша әңгәмә үткәрү;

мөрәҗәгать итүчегә вакытлыча эшкә урнашуга икедән артмаган юллама рәсмиләштерү һәм бирү;

гражданинга әңгәмә узу вакытлары һәм эш бирүче тамгасы белән вакытлыча эшкә урнашуда катнашу өчен бирелгән юлламаны тапшыру кирәклеге турында хәбәр итү;

гражданинның тәкъдим ителгән эш вариантларыннан язмача баш тартуы;

Физик затлар регистрында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен теркәү.

3.9.5. Мәшгульлек үзәгенә алдагы тапкыр килгән вакытта бирелгән юллама буенча вакытлыча эшкә урнашкан очракта, мөрәҗәгать итүчегә вакытлыча эшкә урнашу чорында матди ярдәм күрсәтү турында карар кабул итү

Гражданин тарафыннан гражданинны вакытлыча эшләргә урнашкату турында эшкә алучы тамгасы белән юлламаны һәм эшкә алучы белән билгеле бер вакытка төзелгән хезмәт килешүен мәшгульлек үзәге белгеченә тапшыру административ гамәлне үти башлау өчен нигез булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече мөрәҗәгать итүчегә вакытлыча эшкә урнашу чорында матди ярдәм күрсәтү яки аны күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә.

Карар кабул иткәндә, мәшгульлек үзәге белгече мәшгульлек үзәге һәм эш бирүче арасында төзелгән килешүдә вакытлыча эшкә урнашу чорында гражданнарга матди ярдәм күрсәтүне күздә тоткан нигезләмәләр булуын яки булмавын исәпкә ала.

Үтәү вакыты: процедура процедура башланганнан бирле бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: вакытлыча эшкә урнашу чорында мөрәҗәгать

итүчегә матди ярдәм күрсәтү яисә аны күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү һәм мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.9.6. Матди ярдәм күрсәтү турында уңай карар кабул ителгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә вакытлыча эшкә урнашу чорында матди ярдәм билгеләү

Административ гамәлне үти башлау өчен вакытлыча эшкә урнашу чорында гражданинга матди ярдәм күрсәтү турында мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан кабул ителгән карар нигез булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече:

уңай карар кабул ителгән очракта, вакытлыча эшкә урнашу чорында матди ярдәм күрсәтү турында боерык проекты (әлеге Регламентка 5 нче кушымта), матди ярдәм күрсәтү чорының дәвамлылыгын күрсәтеп, рәсмиләштерә;

мөрәҗәгать итүчегә вакытлыча эшкә урнашу чорында күрсәтелә торган матди ярдәмнең айлык күләме, аны исәпләү тәртибе һәм түләү шартлары турында мәгълүмат җиткерә;

тискәре карар кабул ителгән очракта, вакытлыча эшкә урнашу чорында матди ярдәм күрсәтүдән баш тарту турында боерык проекты (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта) рәсмиләштерә;

вакытлыча эшкә урнашу чорында матди ярдәм күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту турында боерык проектын раслау өчен мәшгульлек үзәге директорына тәкъдим итә.

Үтәү вакыты: процедура процедура башланганнан бирле бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе:

вакытлыча эшкә урнашу чорында мөрәҗәгать итүчегә матди ярдәм күрсәтү турында боерыкны рәсмиләштерү һәм мөрәҗәгать итүчегә матди ярдәмне исәпләү тәртибе һәм түләү шартлары турында мәгълүмат җиткерү;

вакытлыча эшкә урнашу чорында мөрәҗәгать итүчегә матди ярдәм күрсәтүдән баш тарту турында боерык рәсмиләштерү.

3.9.7. Эш бирүчедән гражданинның вакытлыча эшкә урнашуда катнашуын раслый торган белешмәләр алынган очракта, вакытлыча эшкә урнашу чорында мөрәҗәгать итүчегә матди ярдәм күчерү

Административ гамәлне үти башлау өчен үзенә карата вакытлыча эшкә урнашу чорына матди ярдәм күрсәтү турында карар кабул ителгән гражданинның вакытлыча эшкә урнашуда катнашуын раслый торган документларның эшкә алучыдан алынуы нигез булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече мөрәҗәгать итүченең эшсез дип танылуы турындагы боерыкны (эшсез гражданнар һәм белем алган эшсез затлар) һәм вакытлыча эшкә урнашы чорына матди ярдәм күрсәтелүе турындагы боерыкны үз эченә алган шәхси эшен мәшгульлек үзәгенең гражданнарга социаль түләүләр билгеләү һәм күчерү функциясен гамәлгә ашыра торган белгеченә тапшыра.

Мәшгульлек үзәгенең гражданнарга социаль түләүләр билгеләү һәм күчерү функциясен гамәлгә ашыра торган белгече:

халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә ведомство мәгълүмат системасында килешү шартлары нигезендә эш бирүче тарафыннан тапшырылган, мөрәҗәгать

итүченең күрсәтелгән эшләрдә (билгеле бер вакытка хезмәт килешүе, эшкә алу турында боерык, эштән куу турында боерык, эш вакытын исәпкә алу табеле һ.б.) катнашуын раслый торган документларның күчермәләре нигезендә аның күләмен билгеләп, айлык матди ярдәмне исәпли;

матди ярдәм алучыны исәпкә алу карточкасы банкын халыкны эшкә урнаштыру өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар – физик затлар регистрында тутыра, бастырып чыгара торган җайланмадан чыгара һәм мөрәҗәгать итүченең шәхси эшенә теркәп куя;

вакытлы эшләрдә фактта катнашкан көннәр саны өчен матди ярдәм күләме турындагы белешмәләрне матди ярдәм алучыны исәпкә алу карточкасы банкында халыкны эшкә урнаштыру өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар – физик затлар регистрында кертә, бастырып чыгара торган җайланмадан чыгара һәм мөрәҗәгать итүченең шәхси эшенә теркәп куя;

вакытлы эшләрдә катнашу көннәренең факттагы саны өчен матди ярдәм күләмен исәпләү турындагы мәгълүматны матди ярдәм түләү буенча исемлек кәгазенә теркәп куя.

Процедураларны үтәү вакыты: процедуралар процедура башланганнан соң бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гражданнарга социаль түләүләрне билгеләү һәм күчерү функциясен башкара торган мәшгульлек үзәге белгеченә тапшырылган мөрәҗәгать итүченең шәхси эше, җәмәгать эшләрендә фактта катнашкан көннәр өчен матди ярдәм күләме күчерү турында матди ярдәм түләү буенча исемлек кәгазенә теркәлгән белешмәләр.

3.9.8. Әлеге Регламентның 3.9.1 пунктындагы 4-6 пунктчаларында каралган административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү нәтиҗәләрен Физик затлар регистрына кертү

Административ гамәлне үти башлау өчен мәшгульлек үзәге белгеченең әлеге Регламентның 3.9 пунктының 4-6 пунктчаларында каралган гамәлләрне башкаруы нигез булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече матди ярдәм күрсәтү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен Физик затлар регистрында терки.

Процедураларны үтәү вакыты: процедуралар процедура башланганнан соң бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәләре: матди ярдәм күрсәтү турындагы боерыкны Физик затлар регистрында теркәү.

3.9.9. Мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүчегә халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары белән хезмәттәшлек итү очрагында туры килә торган эш эзләү мөмкинлеге турында мәгълүмат җиткерү

Гражданинның халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать итүе административ гамәлне үти башлау өчен нигез булып тора.

Мәшгульлек үзәге белгече мөрәҗәгать итүчегә, гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне дә кертеп, халыкны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итә алуы турында мәгълүмат җиткерә.

Үтәү вакыты: процедура процедура башланганнан бирле бер минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә, ул мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән очракта, мәшгульлек хезмәте органнары ярдәмендә тиешле эш эзләү мөмкинлеге белән таныштыру.»;

3.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10. Техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны яки шуңа охшаш хатаны) төзәтү

Административ процедураны үти башлау өчен гражданинның техник хатаны төзәтү турында язмача мөрәҗәгате нигез булып тора.

Техник хата мөрәҗәгать итүче тарафыннан, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 2 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгән очракта төзәтелә.

3.10.1. Мәшгульлек үзәге белгече:

- техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы);

- вакытлыча эшкә урнашуга юлламаны яңадан рәсмиләштерә;

- гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә вакытлыча эшкә урнашуга юлламаны яңадан рәсмиләштерү турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, вакытлыча эшкә урнашу өчен яңадан рәсмиләштерелгән юллама.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.11-3.13 пунктларын өстәргә:

«3.11. Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат бирү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) гаризаны мәшгульлек үзәгенә җибәрү.

3.11.1. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү

Административ процедураны башкару өчен гражданинның күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгате нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен күпфункцияле үзәккә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны

күпфункцияле үзәк (http://mfc16.tatarstan.ru/) сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалануның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

3.11.2. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

Мөрәҗәгать итүченең вакытлыча эшкә урнаштыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гаризасы һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар бирүе административ процедураны үти башлау өчен нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы заты аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урынына документлар тапшыра.

Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.11.3. Гаризаны мәшгульлек үзәгенә җибәрү

Әлеге Регламентның 3.1.2 пунктчасы нигезендә күпфункцияле үзәк белгече тарафыннан кабул ителгән һәм теркәлгән гариза административ процедураны үти башлау өчен нигез булып тора.

Күпфункцияле үзәк белгече гаризаны мәшгульлек үзәгенә җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында, мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – мәшгульлек үзәгенә юлланган гариза.

3.12. Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү

Административ процедураны үти башлау өчен гражданин тарафыннан күпфункцияле үзәккә мәшгульлек үзәге тарафыннан бирелгән бәяләмәдә киткән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итүе нигез булып тора.

Мәшгульлек үзәгендә бирелгән бәяләмәдәге хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турындагы гаризаны мөрәҗәгать итүче шәхсән яки ышанычлы заты аша

күпфункцияле үзәккә язмача тапшыра.

Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.13. Техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны мәшгульлүек үзәгенә юллау

Административ процедураны үти башлау өчен техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән мөрәҗәгать нигез булып тора.

Күпфункцияле үзәк белгече мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәк арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, әмма гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны мәшгульлек үзәгенә җибәрә.

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның (учреждениенең), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.»;

Регламентның 6 нчы бүлеген гамәлдән чыккан дип танырга;

Регламентка 1 нче кушымта турында:

номерлы баш исемендә һәм атамасында «урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзли торган 18 яшьтән 20 яшькәчә эшсез гражданнарны» сүзләрен «урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче таблица исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы»;

2 бүлекнең «Вазыйфа» графасында «Социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлеге җитәкчесе» сүзләрен «Халыкны эш белән тәэмин итүнең актив сәясәт чараларын гамәлгә ашыру бүлеге җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентның 2 нче кушымтасында номерлы баш исемендә һәм текстта «урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзли торган 18 яшьтән 20 яшькәчә эшсез гражданнарны» сүзләрен «урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм

алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентның 3 нче кушымтасының номерлы баш исемендә «урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзли торган 18 яшьтән 20 яшькәчә эшсез гражданнарны» сүзләрен «урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка 4 нче кушымтада:

номерлы баш исемендә һәм кушымта текстында «урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзли торган 18 яшьтән 20 яшькәчә эшсез гражданнарны» сүзләрен «урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны» сүзләренә алмаштырырга;

«2.9 пункт нигезендә» сүзләрен «2.8 пункт нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентның 5 нче кушымтасының номерлы баш исемендә «урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзли торган 18 яшьтән 20 яшькәчә эшсез гражданнарны» сүзләрен «урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентның 6 нчы кушымтасының номерлы баш исемендә «урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзли торган 18 яшьтән 20 яшькәчә эшсез гражданнарны» сүзләрен «урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны» сүзләренә алмаштырырга.